**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**«02» апрель 2021 ел.** **№ 74**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2014 елның 08 декабрендәге 404 нче номерлы «Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы «Муниципаль вазыйфа яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2014 елның 08 декабрендәге 404 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә (Советның 28.12.2015 № 34, 07.02.2018 № 192 карарлары редакциясендә)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктта 3 абзацта «оешмаларның)» сүзеннән соң «, цифрлы финанс активларының, цифрлы валютасының» сүзләрен өстәргә;

1.2. 13 пунктта «оешмаларның)» сүзеннән соң «, цифрлы финанс активларының, цифрлы валютасының» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин